МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.12.2025 Казан ш. № 771-пр

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

05.04.2023 № 225-пр «Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

08.07.2025 № 409-пр «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.04.2023 № 225-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында».

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
26.12.2025 № 771-пр
боерыгы белән расланды

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасының дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели.

Бу Регламентның көче җир кишәрлеге формалаштырылмаган һәм Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында (алга таба – ЕГРН) аның турында белешмә булмаган очракларга карый, яки җир кишәрлеге чикләрен «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законга туры китереп төгәлләштерү сорала.

1.2. Гариза бирүчеләр булып сатулашуларсыз гына җир кишәрлеге алырга хокукы булган физик затлар, шул исәптән, шәхси эшмәкәрләр, һәм юридик затлар санала, соралган җир кишәрлеген булдырырга кирәк булган яисә җир кишәрлегенең чикләре төгәлләштерүне таләп иткән очракларга да карый.

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) эш йөртә.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (белгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.
1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүченең категорияләренә (билгеләренә) туры китереп күрсәтелә, аның турында белешмәләр “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” һәм “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат

системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – туры килгән тәртиптә – хезмәтләр реестры, Бердәм портал) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе
2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар, ул әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән формада.

2. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында Министрлык карары (хат), ул әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән формада.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында реестр язуы формалаштыру каралмаган.
2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләти мәгълүмат системасында теркәлми.
2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүне гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:
гариза бирүченең шәхсән үзенә язмача яки почта аша хат белән;
электрон документ формасында электрон почта адресы буенча һәм (яки) Бердәм порталдагы яки “Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы), “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмати система” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба - ЕИС «Имущество») шәхси кабинетына;
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба - МФЦ) Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:

гариза бирүченең шәхсән үзенә язмача яки почта аша хат белән;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына, гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша мөрәҗәгать итсә (техник мөмкинлекләр булса);

МФЦда Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан почта аша юлланылган яки шәхси тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Министрлыкта гариза һәм документлар регистрацияләнгән көннән соң 15 эш көне эчендә (гариза кергән көннән соң 20 календарь көннән дә артык түгел) күрсәтелә.

2.4.2. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинет аша бирелгән булса, гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер һәм Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетта күренеп торучы «Документларны тикшерү» статусы куелган көннән соң Министрлык тарафыннан 15 эш көне эчендә (гариза кергән көннән соң 20 календарь көннән дә артык түгел) күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте Министрлыкта гариза һәм документлар регистрацияләнгән көннән соң, шулай ук, МФЦ Регламентында каралган срокны да истә тотып, 15 эш көне эчендә (гариза кергән көннән соң 20 календарь көннән дә артык түгел) күрсәтелә.

2.4.4. Әлеге Регламентның 2.12.1, 2.12.2 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булмаса, җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасы Министрлыкта регистрацияләнү датасында Министрлыкта башка затның алдарак тапшырылган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгате булса, аңа беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасы, соңрак кергәннеке белән өлешчә яисә тулысынча тәңгәл килсә, җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында соңрак кергән мөрәҗәгатьне карау срогы туктатылып тора һәм кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр ителә. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында соңрак кергән мөрәҗәгатьне карау срогы алдан юлланган яки тапшырылган җир кишәрлеге урнашу схемасы раслану турында карар кабул иткәнче яисә күрсәтелгән схеманы раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнче туктатылып торыла.

2.4.5. Җир кишәрлеге ясала торган җир кишәрлегенең урнашу схемасын “Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль законның $3^5$ статьясы (алга таба - № 137-ФЗ Федераль закон) нигезендә килештерергә кирәк булган очракта, Регламентның әлеге 2.4.1 – 2.4.3 пунктларында күрсәтелгән срок җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать кергәннән соң 35 көннән дә артык булмаган вакытка кадәр озайтыла ала.

2.4.6. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы гариза кергәннән соң 35 календарь көннән дә артык була алмый.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Республика порталны, Республика порталын, ЕИС «Имущество»ны, Министрлыкның рәсми сайтын кулланган башка түләүләр каралмаган. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты - 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросын регистрацияләү срогы

2.7.1. Запрос һәм документлар кергән бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос МФЦдан кергән көнне Министрлык тарафыннан регистрацияләнә.

2.7.2. Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦдан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән регистрация номерлы расписка бирелә.

2.7.3. Гариза Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Бердәм портал, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү ала.

2.7.4. Гариза почта аша юлланса, гариза бирүчегә гариза Министрлыкка кергән көнне электрон почта белән гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү юллана.

2.7.5. Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, гариза бирелгән көнне министрлык хезмәткәре гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән расписка бирә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен МФЦда күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Министрлыкның дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлегенә (алга таба – Бүлек) мөрәҗәгать итсә, консультация бирелә ала.

2.10.3. Дәүләт хезмәте хезмәттәшлек турында тиешле килешү булган очракта, гариза бирүченең яшәү урынына яки фактик торган (булган) урынына карамастан (физик затлар өчен, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп), яки урнашкан урынына карамастан (юридик затлар өчен) үзе сайлаган теләсә кайсы МФЦда экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

2.10.4. МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге, шул исәптән МФЦда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле запросны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча МФЦга җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү мөмкинлеге каралган.

2.10.6. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм портал, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Бердәм портал, Республика порталы , ЕИС «Имущество»аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш)

тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Бердәм портал, Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Бердәм портал, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.10.7. Запрос формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзалланган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган запросларга да.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче Министрлыкның, МФЦның кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә каршылык тудырмый.

2.10.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.11. Техник мөмкинлек булганда, җир кишәрлеген электрон документ рәвешендә урнаштыру схемасын әзерләү Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә кызыксынган зат тарафыннан пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын яисә башка технологик һәм программа чараларын кулланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.11.1. Закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән: алар мөрәҗәгать итүче үзе мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документларга бүленә.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең

тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту һәм соңыннан аларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гариза Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{17}$ статьясындагы 1 пункты нигезләмәләренә туры килми (алга таба - РФ ҖК);
2) документларны тиеш булмаган органга тапшыру;
3) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итү формасы шушы регламентның 9 нчы кушымтасында китерелгән.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен түбәндге шарт нигез булып тора:

Әгәр дә Министрлыкка кергән җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен анық урнашу схемасы, башка затның алдарак тапшырылган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгатенә беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен анық урнашу схемасына өлешчә яисә тулысынча туры килсә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору турында хәбәр итү формасы шушы Регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.3. Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:
1) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гаризага беркетелгән җир кишәрлеге урнашу схемасы РФ ҖК $11^{10}$ статьясындагы 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый;

2) ясаласы җир кишәрлеге РФ ҖК $39^{16}$ статьясының 1 - 13, $14^{1}$ - 19, 22 һәм 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча гариза бирүчегә бирелә алмый;

3) чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә анықланырга тиешле җир кишәрлеге гариза бирүчегә РФ ҖК $39^{16}$ статьясының 1 – 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый.

4) мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны кире алу.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү формасы шушы Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шулай ук әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), административ процедура таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатланырга рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын күздә тоткан бүленеш каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене профильләү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктарып тору;

4) ведомствоара мәгълүмати арадашлык;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

7) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан эшләү (проактив) режимында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның запросы статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат аша;
– Бердәм портал аша;
– Республика порталы аша;
– ЕИС «Имущество» аша;
– башка сервислар һәм ысуллар кулланып (булса).

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы – ЕИС «Имущество» (http://lk.eisestate.tatar.ru);
5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – Министрлык;
6. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – МФЦ.
7. Россия Федерациясе Җир кодексы – РФ ҖК.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар | Физик зат | 1А |
| 2. | | Юридик зат | 2А |
| 3. | | Шәхси эшмәкәр | 3А |
| 4. | | Гариза бирүченең вәкиле | 4А |

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүче үзе тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1. | 1А-4А | Кәгазь документ формасындагы гариза | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 2. | 1А-4А | Электрон формадагы гариза | Бердәм портал, Республика портал, ЕИС «Имущество» (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) |
| 3. | 1А-4А | Шәхесне раслаучы документ | МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4. | 4А | Гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 5. | 1А-4А | Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр тапшырылган башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар искәрмә булып тора. | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 6. | 1А-4А | Соралган җир кишәрлеген ясарга кирәк булган һәм әлеге җир кишәрлеге ясаласы чикләрнең территориясен ызанлау проекты булмаган очракта, җир кишәрлегенең урнашу схемасы. | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 7. | 2А, 4А | Гариза бирүче чит ил юридик заты булса, юридик затның чит дәүләтнең законнарына туры китереп дәүләт теркәве узуы турындагы документларының рус теленә расланган тәрҗемәсе | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 8. | 2А, 4А | «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзалары реестры, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында яисә җир кишәрлеген түләүсез файдалану турында гариза ширкәт өчен тәгаенләнгән булса. | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документлар | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | 1А-4А | 1. Бинага, корылмага хокук турында ЕГРНнан өземтә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр); | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 2. | 1А-4А | Җир кишәрлеге турында ЕГРН өземтә, ТР буенча Росреестрдан; | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 2А, 4А | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә (алга таба – ЕГРЮЛ), Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ). | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4. | 3А, 4А | Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРИП) белешмә, ТР буенча ФСХИдан; | Бердәм портал, Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |

Искәрмә.

Техник мөмкинлекләр булганда, кызыксынган зат җир кишәрлеге урнашу схемасын электрон документ рәвешендә әзерләүне Россия Федерациясе Җир

кодексы нигезендә пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын яисә башка технологик һәм программа чараларын файдаланып гамәлгә ашыра ала.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А – 4А | гариза РФ ҖК 39[15] статьясының 1 пунктына туры килми |
| 2. | 1А – 4А | документларны тиеш булмаган органга тапшыру |
| 3. | 1А – 4А | әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А – 4А | Әгәр дә Министрлыкка кергән җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасы, башка затның алдарак тапшырылган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгатенә беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасына өлешчә яисә тулысынча туры килсә. |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А – 4А | җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гаризага беркетелгән җир кишәрлеге урнашу схемасы РФ ҖК 11[10] статьясындагы 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый; |
| 2. | 1А – 4А | ясаласы җир кишәрлеге РФ ҖК 39[16] статьясының 1 - 13, 14[1] - 19, 22 һәм 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча гариза бирүчегә бирелә алмый; |
| 3. | 1А – 4А | чикләре «Күчемсез милекнең дәүләт регистрациясе турында» 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә анықланырга тиешле җир кишәрлеге гариза бирүчегә РФ ҖК 39[16] статьясының 1 – 23 подпунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә |

| | | |
|---|---|---|
| | | алмый |
| 4. | 1А – 4А | дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать гариза бирүче инициативасы буенча кире алынуы |

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
_______________________________

(кемнән) ________________________________
(физик затлар өчен – фамилия, исеме, этисенең исеме (соңгысы - булганда), яшәгән урыны, шәхесен раслаучы документ реквизитлары, ИНН

_________________________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы,урнашкан урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛда теркәлүе турында мәгълүмат, ОГРН, ИНН)
_________________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында
гариза

Сездән _______________________________________ нигезендә,

(РФ ҖК 39.3 ст. 2 п., 39.5 ст., 39.6 ст. 2 п., яки 39.10 ст. 2 п. каралган нигезләр күрсәтелә).

______________________________________________________максатларында

(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)

___________________________________________________________________________

(гариза бирүче җир кишәрлеген алырга теләгән хокук төре)

_______ кв.м. мәйданлы, кадастр номеры ________:___, ___________________

файдалануга рөхсәте булган, _______________ категорияле,

_________________________ ______________________ адресы буенча урнашкан

(җир кишәрлегенең урнашу урыны күрсәтелә)

җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүегезне сорыйм.

Өстәмә белешмә (аста күрсәтелгән шартлар булганда тутырыла):

______________________________________________________________________

дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алынган җир кишәрлегенә алмашка бирелә торган җир кишәрлеге булса, җир кишәрлегенең дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алынуы турында карар реквизитлары;

________________________________________________________________________________

җир кишәрлеге территориаль планлаштыру һәм (яки) территориянең планировка проектында каралган объектларны урнаштыру өчен бирелә икән, территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территориянең планировка проектын раслау турында карар реквизитлары;

___________________________________________________________________________________________сор алган җир кишәрлегенең ясалуы территорияне ызанлау проектында күрсәтелгән икән, территорияне ызанлау проектын раслау турында карар реквизитлары

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр тапшырылган башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән исемлектә каралган документлар, вәкаләтле органга ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибендә бирелә торган документлар искәрмә булып тора

2) җир кишәрлегенең урнашу схемасы *(соралган җир кишәрлеген ясарга кирәк булса һәм әлеге җир кишәрлеге ясаласы чикләрнең территориясен ызанлау проекты булмаса);*

3) гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ *(җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать итсә);*

4) юридик затның чит дәүләтнең законнарына туры китереп дәүләт теркәве узуы турындагы документларының рус теленә расланган тәрҗемәсе (гариза бирүче чит ил юридик заты булса);

5) «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзалары реестры, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында яисә җир кишәрлеген түләүсез файдалану турында гариза ширкәт өчен тәгаенләнгән булса.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәгеләргә бирүегезне сорыйм:

Бердәм порталда, Республика порталында, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетка;

электрон документның кәгазьгә төшергән экземплярлары формасында Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенә.

Гариза бирүче(ләр)нең, ышанычнамә буенча вәкилләрнең имзасы (_______№_____________

_________________________________________/______________________/

(вәкилнең фамилия, имя, әтисе исеме (соңгысы – булганда), имзасы)

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштырудан катнашырга рөхсәтемне бирәм _________________________.

________________ ___________________ ( __________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ.(соңгысы булса)

Искәрмә:
Гариза кабул ителде: «___»_________ 20__ г. ________________________________
гаризаны алган Бүлек белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү
турында гаризага
кушымта

Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гаризага теркәлгән документлар исемлеге

| Документ атамасы | Битләр саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

_____________________________________ ________________________________

(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вазыйфаи заты

________________________________ ____________________________

(фамилия, инициаллар) (имза)

Бөтен документлар 1 данә бирелә

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

(Үрнәк форма)

(Орган бланкы)

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында

Гаризаны ________________ (ИНН _____), Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтәне _____ № _____, № _____, дәүләт күчемсез милек кадастры белешмәләрен карап, Россия Федерациияcе Җир кодексының ________ статьяларына туры китереп.

1. Дәүләт милкендә булган, ___________ территориаль зона чикләрендә урнашкан ________________ категорияле җирләрдән җирдән ясала торган _____________________кв.м. мәйданлы территориянең кадастр планында урнашкан җир кишәрлегенең тәкъдим ителгән схемасын расларга.

2. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән ______ кв.м.лы мәйданлы ясалган җир кишәрлегенә рөхсәт ителгән файдалану төрен ___________________________________ билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән ______ кв.м.лы мәйданлы ясалган җир кишәрлегенә адрес бирергә: ______ .

4. Мәйданы ______ кв.м.лы, ______________________________ категорияле җирләрдән ясалган, ______________________ адресы белән урнашкан җир кишәрлеген бирүне алдан килештерергә, яшәгән адресы _________________________, паспорт сериясе_________________№_____________ бирелгән______________________.

5. Әлеге боерыкның 4 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү ул ясалу сәбәпле җир кишәрлегенең дәүләт кадастр учёты үтү шарты үтәлүенә бәйле тормышка ашырылачак.

6. ___________________ ышанчынамәсез генә соралган җир кишәрлеген дәүләт кадастр учётына алуны гамәлгә ашыру турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Дәүләт җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге җитәкчесенә әлеге күрсәтмәне кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрүне тәэмин итәргә.

8. Дәүләт җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге җитәкчесенә әлеге боерыкның 4 пунктында күрсәтелгән ясала торган җир кишәрлегенең адресы турында белешмәләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт адреслар реестрында урнаштыруны тәэмин итәргә.

9. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасарына йөкләргә.

Министр ___________________________ (Фамилия, инициаллар)

Имза

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту карарының тәкъдим ителгән формасы

Җитәкчегә
______________________________________
(юридик зат атамасы)

______________________________________
(физик затның фамилиясе, инициаллары)

____________________________ № _______ регистрацияләнгән гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында түбәндәге нигезләрдән чыгып карар кабул ителде:___________________.

Баш тарту сәбәпләренә ачыклык кертү:________________________________________.

__________________________________________________________________
(гариза бирүче булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы баш тартуга китергән документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, баш тарту сәбәпләре турында, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән, туры килмәве дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр ителә)

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: _____________________________________.
(Хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Күрсәтелгән кимчелекләр бетерелгәннән соң, сез Министрлыкка дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тарту шикаятьне министрлыкка җибәрү юлы белән судка кадәр һәм шулай ук суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

Вазыйфаи зат ______________ ____________________(Фамилия, инициаллар)
органның вазыйфаи заты имзасы

Башкаручы (фамилия, инициаллар)

___________________________
(башкаручының контактлары)

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

(Орган бланкы)

Белдерү кәгазе

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы
_______________________________________________________________________________
(Ф.И.ӘИ. физик зат, гариза бирүче юридик зат атамасы)
гариза № _______ _____._____._________, мөрәҗәгатьне караганнан соң дәүләт хезмәте күрсәтүне түбәндәге сзбзрләр аркасында туктатуын хәбәр итә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза беркетелгән җир кишәрлеген ясау өчен аның урнашу схемасы кергән датада Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карамагында әлеге схемаларда карала торган җир кишәрлеген һәм җир кишәрлекләрен бүлүнең башка зат тарафыннан бирелгән схемасы өлешчә яисә тулысынча туры килә (Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{15}$ статьясының 6 пункты).

Вазыйфаи зат ___________________________(Фамилия, инициаллар)
органның вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (Ф.И.ӘИ.)

___________________________

(башкаручының контактлары)

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
9 нчы кушымта

(Орган бланкы)

Белдерү кәгазе

______________________________________________________________________
Ф.И.ӘИ. физик зат, гариза бирүче юридик зат атамасы)
____________________________________________ ________турында мөрәҗәгате сәбәпле

____________________________________________________________________________

Түбәндәгеләр нигезендә: _______________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге сәбәпләр аркасында документларны кабул итүдән баш тарту һәм аларны кире кайтару турында карар кабул ителде:

1.
2.

Вазыйфаи зат ____________________________________(Фамилия, инициаллар)
органның вазыйфаи заты имзасы)

Башкаручы (Ф.И.ӘИ.)

______________________________

(башкаручының контактлары)